yulbasma

Миләүшә
Гафурова

Рәссам
Галина Дук

# Дилбәр белән Фирүзәнең гаҗәеп тормышы

•Баз вакыйгасы•



УДК 821.512.145
ББК 84
Г24

Дилбәр белән Фирүзәнең гаҗәеп тормышы. Баз вакыйгасы / Миләүшә Гафурова. – Казан : «Юлбасма» нәшр., 2022. – 60 б.

ISBN 978-5-6048800-1-2

Әдәби-нәфис басма
Мәктәп яшендәге балалар өчен
Гафурова Миләүшә Равил кызы
**Дилбәр белән Фирүзәнең гаҗәеп тормышы. Баз вакыйгасы**
Казан. «Юлбасма» нәшрияты. 2022

Рәссам Галина Дук
Компьютерда биткә салучы, леттеринг Соня Лигостаева
Корректор Эльза Нәбиуллина
Бизәлеш мөхәррире Гүзәл Гарипова
Әдәби мөхәррир Йолдыз Миңнуллина
Җаваплы мөхәррир Гүзәл Хәсәнова



Литературно-художественное издание
Для детей школьного возраста
Гафурова Миляуша Равилевна
Удивительная жизнь Дильбар и Фирузы. Случай в погребе
Казань. Издательство «Юлбасма». 2022
На татарском языке

Оригинал-макет подписан в печать 30.09.2022. Формат 84х108/16.
Тираж 1000 экз. Заказ О-2306.
ООО «Юлбасма». 420021. Казань. Тел.: 8(917)893-42-99. E-mail: info@yulbasma.com.

Отпечатано в филиале АО «Татмедиа» Полиграфическо-издательский комплекс «Идел-Пресс». 420066. Казань, ул. Декабристов, 2.

6+ Знак информационной продукции согласно ФЗ от 29.12.2010 г. № 436-ФЗ
Правовую охрану интеллектуальной собственности издательства обеспечивает ИП Хасанов Р. А.

**Издательство «Юлбасма»**
www.yulbasma.com
**Книжный магазин «Юлбасма»**
www.yulbasma.ru

© Гафурова Миляуша, текст, 2022
© Дук Галина, иллюстрации, 2022
© ООО «Юлбасма», издание на татарском языке, 2022





# Ике авыл

Таң саен кояш, юрган астыннан чыгып торган борыныңны кытыклап киткәннән соң, җир йөзе буйлап авылларны, шәһәрләрне, кешеләрне, йортларны, агачларны, тауларны санап йөри. Ул берүзе җир йөзендәге бөтен галимнәрдән күбрәк белә.

Кояш таң саен юрган астыннан чыгып торган борыныңны кытыклый да янәшә генә торган ике авылны уятырга китә. Ул авылларның берсе борынгы куе урманга терәлеп тора, ә икенчесе шул авыл янында калкып торган мәңгелек тауда утыра.





Билгеле инде, биектән бөтен нәрсә яхшырак күренә, шуңа тауда яшәүчеләр кояшны да беренчерәк күрәләр.

Фирүзә тау авылында яши. Ул һәр көнне таң атканчы ук сикереп тора да авылга килгән кояшны каршы ала.

Дилбәр ул вакытта урманга терәлеп торган кечкенә йортта, йомшак юрган астында иң кызык төшен күреп ята.

Кояшны Дилбәрдән беренчерәк күрер өчен шулай иртә тора да инде Фирүзә.

Чынлыкта, Фирүзә белән Дилбәр бик дус. Шулай булгач, алар яшәгән гаиләләр дә, алар яшәгән авыллар да бер-берсе белән дус булмыйча кала алмый. Аларга бәйрәм саен кунакка йөрешергә, көн саен хәл белешергә туры килә.







# Дилбәр белән Фирүзә

Дилбәр өченче класста укый, Фирүзә — дүрттә. Икесенең дә абыйлары бар. Өстәвенә Фирүзәнең абыйсы — Дилбәргә дә абый, Дилбәрнең абыйсы — Фирүзәгә дә абый, чөнки алар — туганнар. Шуңа бу икәү туганнан бирле дус, ә аларның ярышуы туганчы ук башланды.

Беренче ярышта Фирүзә җиңде: ул Дилбәрдән беренчерәк туды.

Аның каравы, Дилбәр йөзәргә өйрәнүдә дә, тимераякка басуда да беренчерәк булды. Берсенең дә үзе карап үстерә торган җәнлеге юк иде, Фирүзәгә узган елны әрлән алдылар. Дилбәр әтисе белән әнисен: «Без дә алыйк!» — дип үгетләп карады. Тик алар: «Әнә Мәхмүткә әйт, тычкан тотып бирсен, читлеккә утыртып куярбыз», — дип кенә көлделәр. Мәхмүт — Дилбәрләрнең песие.



Хәер, Дилбәр ул елны сәпитле булды. Һәм шунда ук сәпит ярышына әзерләнергә кереште.

Ә Фирүзә — бию бәйгесенә.

Фирүзә соңгы чиректә күбрәк бишле алды. Дилбәр баскетболда күбрәк очко җыйды.





